РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**2022 елның 12 мае** **Чистай шәһәре** **№14/5**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре Башкарма комитеты турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2012 елның 27 августындагы 16/3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Торак кодексына күпфатирлы йортта биналарны үзгәртеп коруны һәм (яки) үзгәртеп планлаштыруны җайга салучы нормаларны тәртипкә салу өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 27 декабрендәге 558-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясы, «Россия Федерациясе Торак кодексына һәм «Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итү фонды турында» Федераль законга авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 27 декабрендәге 473-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Торак Кодексының 14 статьясы нигезендә, муниципаль хокукый актларны хокукый җайга салуны камилләштерү һәм актуальләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре Советы

**Карар итте:**

1. Чистай шәһәре Советының 2012 елның 27 августындагы 16/3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре Башкарма комитеты турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Башкарма комитетның төп бурычлары һәм функцияләре 3 бүлегендәге 3.2 пунктының 4 пунктчасының дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« - билгеләнгән тәртиптә торак биналарны торак булмаган биналарга һәм торак булмаган биналарны торак биналарга күчерү турында карар кабул итә, күпфатирлы йортта торак биналарны үзгәртеп коруны һәм яңадан планлаштыруны килештерә, билгеләнгән тәртиптә муниципаль һәм шәхси торак фондының торак урыннарын, Россия Федерациясе яки Россия

Федерациясе субъекты милкендә булган күпфатирлы йортлардан тыш, яшәү өчен яраксыз дип таный, Россия Федерациясе яки Россия Федерациясе субъекты милкендә булган, авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле күпфатирлы йортлардан тыш;».

2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары М.И. Ксенофонтовка йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәре башлыгы Д.А. Иванов